СОВЕТ ОМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Омары,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422183

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОМАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Омар авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422183

тел.(факс): (85563) 2-82-47; e-mail: Omar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

“02” октября 2017 г. — № 1-27

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 20 сентябрендәге «Референдум үткәрү инициативасы турында» 10 номерлы карары» Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советының 2017 елның 20 сентябрендәге «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2-26 карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советының 2014 елның 2 апрелендәге 2-10 карары белән расланган Гражданнарның үзара салымы турында нигезләмә нигезендә һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Омар авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2017 елның 19 ноябренә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән

кала, 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру;
- Албай торак пунктында зират ягына баручы юлны, Югары Әрнәш торак пунктында Максимов урамы ягына баручы юлны вакташ җәеп ремонтлау;
- авыл җирлегенә караучы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

**1. Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**
Омар авыл җирлеге торак пунктында янгын гидрантлары җайланмаларын сатып алу һәм урнаштыру;
**2. Торак пункт чикләрендә су белән тәэмин итү, су чыгаруны оештыру:**
Рагозино торак пунктында су су этем башнясы сатып алу һәм урнаштыру;
Рагозино торак пунктында, Сикәнәс торак пунктында, Березовский торак пунктында суэтем башняларын койма белән әйләндереп алу;
Омар Починок торак пунктында су алу скважинасын койма белән әйләндереп алу;
3. **Торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны да кертеп):**
урам яктырту объектларын модернизацияләү Омара торак пунктында урам яктырту лампаларын сатып алу һәм алыштыру.
«Әйе» «Юк»

4. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге башлыгы Н.П.Князевага йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Омаравыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе ___ Н.П.Князева